ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТУКАЙ МУНИЦПАЛЬ РАЙОНЫ
КАЛМИЯ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

**КАРАР**

"22" октябрь 2019 ел Калмия авылы №23

**«Хатаны төзәтү турында»**

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Калмия авыл җирлеге Башлыгының 2019 елның 21 октябрендәге 22 номерлы карарының 1 пунктында киткән хаталар белән бәйле рәвештә, Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Тукай муниципаль районының «Калмия авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 13.1 статьясы нигезендә

**КАРАР БИРӘМ:**

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Калмия авыл җирлеге Башлыгының «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Калмия авыл җирлегенең Кырныш авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында» 2019 елның 21 октябрендәге 22 номерлы карарының 1 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«1. Тукай муниципаль районы Калмия авыл җирлегенең Кырныш авылында 2019 елның 01 ноябрендә 10.00 сәгатькә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә.».

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең рәсми стендларында урнаштырып, халыкка игълан итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

4. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Калмия авыл җирлеге Башлыгы Р.Ә.Гарипов